**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 26 мартындагы 6-37 номерлы карары**

**Казан халык депутатлары Советының**
**2005 елның 30 мартындагы 2-23 номерлы**
**«Казан Мэрының вазифаи билгесе» турындагы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, муниципаль хокукый актларны камилләштерү һәм Казан шәһәре символикасын куллану мәсьәләләрен җайга салу максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан халык депутатлары Советының 2005 елның 30 мартындагы 2-23 номерлы «Казан Мэрының вазифаи билгесе» турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Мэрның вазифаи билгесе яңа сайланган Мэрга, ул ант иткәннән соң, Казан шәһәре Думасының яше буенча иң өлкән депутаты тарафыннан тантаналы шартларда тапшырыла»;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Казан Мэрының вәкаләтләре вакыты узгач, Мэрның вазифаи билгесе вакытлыча Казан Ратушасы бинасында саклана».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Казан шәһәре Мэры** **И.Р.Метшин**